КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 август г.Казань № 738

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында» 2020 ел, 1 апрель, 241 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль ярдәмнең аерым чараларын бирү срогын озайту турында» 2020 ел, 1 апрель, 241 нче карарына түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 7 пунктында билгеләнгән, өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә 2020 елның 1 октябренә кадәр 16 яшькә кадәр (гомуми белем бирү оешмасында укучы өчен – алар белем алуны тәмамлаганчы, ләкин аларга 18 яше тулганчы гына) айлык пособие бирүне озайтканда, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алу өчен түләү турында» 2009 ел, 3 декабрь, 1095 нче карары белән расланган, «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган дару чаралары һәм аптека ассортиментындагы башка товарлар сатып алу өчен түләү бирергә.

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 12 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин